ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

«04» март 2025 ел п. Кама № 7

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кама авыл җирлеге составына керүче Бәтке авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2024 елның 26 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Кама авыл җирлеге Бәтке авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кама авыл җирлеге Бәтке авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 наябрендәге 10/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кама авыл җирлеге составына керүче Бәтке авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 26 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2024 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Тукай муниципаль районы Кама авыл җирлеге Бәтке авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2025 елның 18 марта 15.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кама авыл җирлеге составына керүче Бәтке авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 26 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2024 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Тукай муниципаль районы Кама авыл җирлеге Бәтке авылында гражданнар җыены карарына:

«- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау»

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Бәтке авыл җирлеге, Кама авылы, Чкалова ур., 7 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы В.А.Валиева